ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Зеленодольск **КАРАР**

**26.05.2021** шәһәре **№ 1140**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 22 июлендәге №1328 карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасын тормышка ашыру кысаларында, авыл территорияләрендә яшәүче һәм эшләүче, яисә Зеленодольск чикләренә даими яшәү урынына күчәргә һәм анда эшләргә теләк белдергән гражданнарның торак шартларын яхшыртуның һәркем файдалана алырлык булуын арттыру мәсьәләсе буенча җәмәгать торак комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Кадрлар үзгәрешенә һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасын тормышка ашыру кысаларында, авыл территорияләрендә яшәүче һәм эшләүче, яисә Зеленодольск чикләренә даими яшәү урынына күчәргә һәм анда эшләргә теләк белдергән гражданнарның торак шартларын яхшыртуның һәркем файдалана алырлык булуын арттыру мәсьәләсе буенча җәмәгать торак комиссиясе составына (алга таба-Комиссия) үзгәрешләр кертү зарурлыгына бәйле рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1.Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 22 июлендәге №1328 карары белән расланган, «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасын тормышка ашыру кысаларында, авыл территорияләрендә яшәүче һәм эшләүче, яисә Зеленодольск чикләренә даими яшәү урынына күчәргә һәм анда эшләргә теләк белдергән гражданнарның торак шартларын яхшыртуның һәркем файдалана алырлык булуын арттыру мәсьәләсе

буенча җәмәгать торак комиссиясе составы турында»гы карарның 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нурмөхәммәтов Әмир Җәмил улын, Зиннуров Рамил Наил улын, Денисова Лариса Рудольф кызын Комиссия составыннан чыгарырга.

1.2. Комиссия составына Комиссия рәисе сыйфатында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Ольга Александровнаны кертергә;

1.3. Комиссия составына комиссия әгъзалары сыйфатында түбәндәгеләрне кертергә:

Рәхимова Лилия Фәрит кызын, «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты» муниципаль бюджет учреждениесенең торак фонды бүлеге башлыгын;

Ким Наталья Аркадьевнаны, «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты» МКУ әйдәүче белгечен;

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына әлеге карарны урнаштыруны тәэмин итүне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р. Ганиев